**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет**
**Учаллинского сельского**
**поселения Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Советская, д. 51, село Учалле,
Азнакаевского муниципального района,
423317

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы**
**Үчәлле авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**

Совет урамы, 51, Үчәлле авылы
Азнакай муниципаль районы
423317

Тел./факс(885592)36-8-32; E-mail:Uchal.Azn@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«06» август 2018 ел. № 10

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 гыйнварындагы 87 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 33 статьялары нигезендә, Үчәлле авыл җирлегенең 2018 елның 2 июлендәге җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе бәяләмәсе нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 гыйнварындагы 87 номерлы карары белән расланган (2016 елның 22 декабрендәге 46 номерлы, 2016 елның 22 декабрендәге 47 номерлы карарлар редакциясендә) Азнакай муниципаль районының «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләүгә керешергә:

1.1. 36 статьяга. Шәһәр төзелеше регламентлары. Торак зоналары:

- Индивидуаль торак йортлар белән торак төзелешенең территориаль зонасы өчен шәһәр төзелеше регламентларына күчемсез милекне файдалануның төп рөхсәт ителгән төрләренә карата җир кишәрлекләренең максималь чик күләмнәрен билгеләү өлешендә үзгәреш кертергә - 5000 кв.м».

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү эшләрен башкару тәртибен һәм срокларын (1 нче кушымта) нигезендә билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Г.М. Төхвәтуллина

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 18 августындагы №

10 карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү эшләрен башкару буенча якынча сроклар**

| N | «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проектны әзерләү эшләрен уздыру тәртибе | Эшләр уздыру срогы |
|---|---|---|
| 1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү буенча эшләр оештыру. | 2018 елның III кварталы |
| 2.<br><br>2.1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү һәм килештерү.<br><br>Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренең шәһәр төзелеше регламентларына үзгәрешләр кертү, җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен килештерүдә катнашучы хезмәтләрнең һәм ведомстволарның искәрмәләренә шәрехләр әзерләү. | 2018 елның III кварталы |
| 3.<br><br><br>3.1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект турында фикер алышу.<br>Гавами тыңлауларны үткәрү.<br>Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге башлыгына «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге төзелешләренең җирдән файдалану кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект юлламасы Азнакай муниципаль районы «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге төзелешенраслау яисә кире кагу турында карар кабул итү өчен аңа карата мәҗбүри кушымталар (гавами тыңлаулар беркетмәсе һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә) юлламасы аны кабат тәкъдим итү датасын күрсәтеп, авыл җирлеге советына кертү өчен җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре аны эшләп бетерү турында карар кабул итү өчен юллама. | 2018 елның III-IV кварталы |